




# Тамчы

«2 нче санлы Җәлил урта мәктәбе» газетасы

апрель №11 (71) 2016-2017 нче уку елы


**26 нчы апрель—Габдулла Тукай туган көн**

## “Тукай” айлыгына нәтиҗә ясалды

Татар теле һәм әдәбиятына, халкыбызның тарихына, сәнгатенә һәм мәдәниятенә багышланган айлык тәмамланды. Айлыкның соңгы атнасын без бөек шагыйребез истәлегенә багышладык. Ул “Тукай атналыгы” исеме астында узды.




Атналык Тукай шигырьләрен сәнгатьле укучылар бәйгесеннән башланып китте. Бәйге җиңүчеләре бистәнең традицион Шигырь бәйрәмендә чыгыш ясау хокукын яуладылар. Шигырь бәйрәме 26 нчы апрель – шагыйрьнең туган көне көнне үтте. Анда 2 нче “а” сыйныфы укучысы Масалимова Раяна, 5нче”б” дан Гарипова Альбина, 11 нче “б” дан Нургалиева Ландыш чыгышлары өчен Җиңүче дипломына лаек булдылар. 25 нче апрельдә бер төркем укучылар бистәнең Хезмәт Даны музеенда үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә катнаштылар һәм бик матур тәэсирләр белән кайттылар.

27 нче апрель көнне бистәкүләм әдәби бәйге оештырылды. Анда мәктәпләрнең 8нче сыйныф укучыларыннан торган биш кешелек өч



команда көч сынашты. Квест кагыйдәләре буенча командалар бистәнең төрле оешмаларында булып, татар халкының тарихы, сәнгате, әдәбияты, гореф-гадәтләре, республикабызның географиясе буенча белемнәрен күрсәттеләр. Чараны оештыруда хезмәттәшлек күрсәткәннәре өчен, бистәнең ветераннар советына, “Девон” кафесына, Боз сарае, “Батыр” спорт-сәламәтләндерү үзәгенә, “Бүләкләр” кибетенә, балалар китапханәсенә зур рәхмәт белдерәсе килә. Укучыларның эшен тикшерүдә Хезмәт Даны музее, Җәлил үзәк китапханәсе хезмәткәрләре, “Җәлил чаткылары” әдәби берләшмәсе әгъзалары Әнвәр Төхватуллин, Фәйрүзә Хәбибуллинаның өлеше



искиткеч зур булды. Икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучысы Ландыш Камил кызы Шәйдуллина инициативасы белән башланган эш әнә никадәр оешмада теләктәшлек тапты. Квестның масштабын тагын да киңәйтергә кирәк дигән фикер туды. Командалар бистә башлыгы Л.М.Бадиков имзалаган Мактау кәгазьләре белән бүләкләнделәр. Татар халкының гореф-гадәтләрен бик яхшы белгән беренче мәктәп командасы -”Милли җанлы команда”, Г.Тукай иҗаты буенча сорауларга тулы җаваплары белән икенче мәктәп командасы – “Иң әдәби команда", халкыбызның күңел җәүһәрләрен иң шәп белүче гимназия командасы – “Иң тапкыр команда” исеменә лаек булды. Чара тыл ветераны Илгизә апа Мугинова белән очрашу белән тәгәлләнде. Бүгенге матур тормышта яшәвебез, иркенләп белем ала алуыбыз, имин көнебез өчен без әнә шул буын вәкилләренә, Бөек Ватан сугышы каһарманнарына бурычлы булуыбызны онытмаска тиешбез.

Атналык “Тукай безнең күңелләрдә” дип исемләнгән чара белән төгәлләнде. Аны татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гаскарова Л.М. кызы оештырды. Изге җомга көнендә шагыйрьнең якты истәлеген балалар китапханәсендәге чарада да искә алдылар. Анда Г.С.Нуртдинова җитәкчелегендә укучылар катнашты.

Майның беренче атнасы безне “Татар җыры” фестивале белән сәламләячәк. Җиңүчеләрне бүләкләү әнә шул фестиваль кысаларында булачак.

## 4 нче г сыйныфы укучысы Төхбатуллина Элинаның иҗат җимешләре

### Төлке

Төлке үзе кызгылт-сары,
Хәйләкәр әле тагы.
Әллә кайлардан күренә
Маңгаендагы агы.
Авылга төлке килгәнне
Этләр генә беләләр,
Хуҗаларга шуны әйтеп
Өрәләр дә өрәләр

### Әтәч

Әтәч тора бик иртүк
Кычкыра ул шунда ук:
"Кикрикүк."
Чупли тары ярмасын,
Томшык кына
армасын.
Канатлары талмасын.
Кош-кортларга ул хуҗа,

### Безнең гаилә

Гаиләбез безнең олы,
Бик озын аның юлы.
Бабай шаян тагын да
Әйбәт уйный гармунда.
Эти гел мактый үзен,
Әни буйый уң күзен.

### Чәчәкләр

Бөтен үлән арасында,
Ак чәчәкләр уртасында
Үсә бер матур чәчәк.
Бөтен малай аны күргәч,
Кычкырып бер көләчәк:
Әйбәт безнең балачак!



### Су анасы

Яшәде су кырыенда
Зифа буйлы Су кызы.
Калган аның басмада
Гаҗәп алтын тарагы.
Бер малай су кергәндә
Күргән зифа Су кызын.
Басмадан алтын таракны
Алып чапкан, ул - карак.



### *Шүрәле*

Карурманда яши, диләр,
Бик әшәке Шүрәле
Аның нинди икәнлеген
Үзең барып күр әле.
Кәкре-бөкре аяклары,
Бик озын бармаклары.
Тавык җырына ошаган
Шүрәле такмаклары.

### Зайчик

Зайчик, зайчик побегайчик,
Ну, какой ты хулиганчик,
Бегаешь и вертишься
В глазах ярко светишься
Что ты ищешь косенький?
Ну, какой ты миленький.

### Зима

Зима пришла в поселок
Как белый поросенок
И гадкий как утенок
Так рады мы все ей!
С ней нам всем веселей
Нет ее добрей
И, конечно веселей!

### Шмель

Шмель гудит, поет, танцует,
У цветов пыльцу ворует.
В воздухе кружится,
На цветок ложится.
О чем он мечтает
Знаю я точно
Может ему надо
Куда-то срочно.

**Шеф редактор**: Шәйдуллина Ландыш Камил кызы

**Редколлегия**: Зәкиева Азалия, Мөхәммәтгалиева Гүзәл, Насыйбуллин Данияр (6 в)

**Материалны редколлегия әгъзалары һәм шеф-редактор (307 каб.) кабул итә.**